**Авторы публикации**

***Гараева Альмира Кадыровна*** *– кандидат филологических наук, доцент, Казанский федеральный университет*
*E-mail: Almiragaraeva09@yandex.ru*

***Хафизова Алсу Александровна*** *– кандидат филологических наук, доцент, Казанский федеральный университет*
*E-mail:alsou-f@yandex.ru*

**Authors of the publication**

***GaraevaAlmiraKadyrovna*** *– PhD, associate professor, Kazan Federal University*
*E-mail: Almiragaraeva09@yandex.ru*

***Khafizova Alsu Aleksandrovna*** *– PhD, associate professor, Kazan Federal University*
*E-mail: alsou-f@yandex.ru,*

**УДК: 81-2**

# ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНДӘ ОРНИТОНИМНАР (КОШ АТАМАЛАРЫ) УРЫН АЛГАН ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

***К.А. Сахибуллина***

*kadria85@yahoo.com*

***Казан федераль университеты, Казан шәһәре, Россия***

**Аннотация.** Әлеге мәкаләдә татар һәм инглиз телләрендә орнитоним компоненты: ягъни кош атамасы кергән фразеологик берәмлекләр өйрәнелә. Кардәш булмаган телләрнең фразеологиясен чагыштырма планда өйрәнү шул телдә сөйләшүче халыкларның дөньяны күзаллауларын, аларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә ярдәм итә һәм хәзерге тел белеменең актуаль мәсъәләләренең берсе булып тора. Безнең эшебездә татар һәм инглиз телләрендә кош атамасы кергән фразеологизмнарны чагыштырып өйрәнү фразеологик берәмлекләрне формалаштыра торган лингвистик һәм экстралингвистик факторларны ачыкларга ярдәм итә.

**Төп сүзләр:** орнитоним компоненты, фразеологик берәмлекләр, символик мәгънә, ассоциатив мәгънә.

**Өземтә алу өчен:** Сахибуллина К.А. Татар һәм инглиз телләрендә орнитонимнар (кош атамалары) урын алган фразеологизмнар. *Казан лингвистика журналы*. 2019; 4 (2): 13–22.

# PHRASEOLOGICAL UNITS WITH THE ORNITHONYM COMPONENT IN THE ENGLISH AND TATAR LANGUAGES

***K.A. Sakhibullina***

*kadria85@yahoo.com*

***Kazan Federal University, Kazan, Russia***

**Abstract.** Phraseological units with the ornithonym component are discussed in the article. Phraseological units being inherent part of anthropocentric phraseology, especially those with ornithonym component in different languages can be associated with different properties of people. Comparative study of phraseology of two languages, the signs of two languages helps to define the cultural peculiarities of the peoples speaking the languages.

**Keywords:** ornithonym component, phraseological units, symbolic meaning, associative meaning.

**For citation:** Sakhibullina K.A. Phraseological units with the ornithonym component in the English and Tatar languages. *Kazan Linguistic Journal*. 2019; 4 (2): 13–22. (In Tat)

Кардәш булмаган телләрнең фразеологиясен чагыштырма планда өйрәнү шул телдә сөйләшүче халыкларның дөньяны күзаллауларын, аларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә ярдәм итә һәм хәзерге тел белеменең актуаль мәсъәләләренең берсе булып тора. Безнең эшебездә татар һәм инглиз телләрендә кош атамасы кергән фразеологизмнарны чагыштырып өйрәнү фразеологик берәмлекләрне формалаштыра торган лингвистик һәм экстралингвистик факторларны ачыкларга ярдәм итә. Шулай ук, шушы телләр турында милли-мәдәни үзенчәлекләрне күзаллауны конкретлаштырырга ярдәм итә.

Кошлар һәрвакыт кешенең игътибарын җәлеп иткән, ә аларның һавада очуы гадәттән тыш һәм сихри булып тоелган. Кошлар табигать көчләренең гәүдәленеше булып кабул ителгән. Күп очракта кошлар уңай образ яки знак буларак каралган. Кайбер мәдәниятләрдә кошлар авыру турында хәбәр итүче булып торганнар (каргалар, грифлар). Кошның иң киң таралган мәгнәсе булып, кеше күңеле белән тиңләштерү килә. Борынгы кешеләр өчен кошлар Алла

хәбәрләрен җиткерүче буларак күзалланган. Төрле әкиятләрдә кошлар әкият каһарманнарына үз киңәшләрен биреп торганнар [6].

Алга таба татар һәм инглиз фразеологизмнарында бирелгән кош образларын карап китәбез.

ЧЫПЧЫК (SPARROW) – *Чыпчык* борынгы грек алиһәсе Афродитаның атрибуты булып торган. Көнбатыш сәнгатендә җилле хатын кызларны чыпчык тоткан хатын рәсеме белән сурәтләгәннәр [6]. Соры төстәге, кечкенә, гел бер урыннан икенче урынга сикереп йөри торган кош күп кенә татар һәм инглиз фразеологизмнарында кулланылган:

тат. ***чыпчык тезеннән*** – гыйлеме бик сай, аз булуга мисалдан;

***чыпчык кебек бер ботакта тормас*** – тиктормас, түземсез кеше

***чыпчыкның да үз бизмәне*** – һәркемнең үз мөмкинлегенә күрә үз чамасы димәктән;

инг. ***eat like a sparrow*** – чыпчык кебек ашый, аз ашый;

КАРГА (RAVEL, CROW) – көнбатыш европа традицияләрендә бу кошны үлем, сугыш белән бәйләп караганнар. Татарларның карга турында күзаллаулары охшаш, өй тирәсендә карга каркылдаганы ишетелсә кайгы кőтелә дип, ышанганнар [3]. Татар һәм инглиз фразеологизмнарында карга образы аша күпчелек очракта кире бәя бирелә:

тат. ***карга карганың күзен чокымый*** – бергә этлек эшләгән кешеләр бер-берсенә каршы чыкмыйлар;

***кара карга-*** аңсыз, кара надан;

инг. *a* **crow on the thatch, soon death lifts the latch** – түбәгә карга утырса, бу гаиләгә кайгы килә;

***crows do not pick the crow's eyes*** – карга карганың күзен чокымый;

***eat crow*** – үзеңнең җиңелүеңне тану;

Америка индеецларында исә карганың кара каурыйларында бернинди зыян һәм начар билгеләр күрмәгәннәр.

Каргаларның тышкы кыяфәте кешеләрнең дә кыяфәтен сурәтләү өчен кулланылган:

тат. ***тавис каурыйлары таккан карга*** – үзен затлы күрсәтү өчен өс-башына ялтыравыклар таккан арзанлы хатын кыз;

***карга чукырлык та ите калмаган*** – үтә ябык, арык тәнле, бетерешкән кеше;

инг**. *as black as crow*** – карга кебек кап-кара;

***crow's foot*** – карга тәпие, күз тирәсендәге җыерчыклар;

Карга образы предметны, төрле күренешләрне, урын һәм вакытны белдерү өчен кулланыла:

тат. ***карга бураны*** – кара каргалар килер алдыннан була торган язгы җепшек буран;

инг. ***as the crow flies*** – карга очкан кебек, турыга йөрү;

***crow's nest*** – карга оясы тәртипсез;

Төрки халыкларда булган йолаларга бәйле *карга боткасы* (яз ахырларында, сабан туе һәм яңгыр теләү көннәрендә балаларның халыктан май, ярма җыеп, елга буенда казан асып, уен-бәйрәм корулары) фразеологик берәмлеге барлыкка килгән.

КҮГӘРЧЕН (DOVE, PIGEON) – күгәрчен һәрвакыт тынычлык, мәхәббәт, чисталык һәм өмет символы булып килә. Бу инглиз телендә түбәндәге фразеологизмнар барлыкка килүгә нигез булган: *as harmless as a dove* – күгәрчен кебек тыныч; *as innocent as a dove* – күгәрчен кебек бер катлы һ.б. Шул ук вакытта күгәрченнәр хат ташучылар дип саналган [6].

Пар күгәрченнәр исә гасырлар дәвамында мәхәббәт символы булып торалар:

тат. ***бәхет күгәрчене*** – насыйп яр*;*

Төрки халыкларда күгәрченнәрне изге кошка санап йөргәннәр. Шул ук вакытта кайберәүләр аны яратып та бетермәгән, күгәрчен оя корган йортка хәвеф-хәтәрләр алып килә дип санаганнар.

КАЗ (GOOSE) – космогоник күзаллауда хаос кошы буларак тасвирлана. Борынгы Римда исә, каз сугыш алласы белән бәйләп каралган, казлар турындагы билгеле вакыйгадан соң уяулык символы булып та килә. Моннан *казлар рим коткарган* (бу аңгыра дип өстән генә карарга ярамый, башыңның сау калуы шуңардан булмасын дигәннән) фразеологизмы барлыкка килгән [2].

Казларның тышкы кыяфәте һәм үз-үзләрен тотышы түбәндәге фразеологизмнарда чагылыш тапкан:

тат. ***Оясын пычраткан каз кебек*** – кая утырырга уңайсызланып аяк өстендә торучыга карата әйтелә;

***кыйкылдак каз*** – көлеп әйтем, киная. Ата казның корыга тавыш биреп, мактанып кыйкылдап йөрүе күп булса да, сүзе эшкә ашмавы белән мисал китереп әйтем;

инг. ***goose pimples*** – каз тиресе;

***goose step*** – каз атлавы;

***beat goose*** – җылыныр өчен үз-үзеңне суккалау;

Фольклорда каз күп сөйли торган, бераз акылы саерак кош булып сурәтләнә. Шуннан чыгып татар һәм инглиз телләрендә түбәндәге фразеологизмнар барлыкка килгән:

тат. ***Әҗем казы*** – суда йөзә белмәгән кешегә әйтәләр;

инг. ***as silly as goose*** – каз кебек ахмак;

Күп кенә татар фразеологизмнарында казны башка кошлар белән чагыштырып карыйлар:

тат. ***каз урынына карга*** – әйбәт нәрсә көткәндә начары эләгүгә, алдануга мисалдан;

Инглиз фразеологизмнарында исә, каз образына, башкалар белән чагыштырылганда, тискәре бәя бирелә:

инг. ***all one's geese are swan*** – казны аккошка әйләндерү, арттырып сөйләү;

Англиядә башлыча каз каурые белән язганнар. Башта "каз каурые" язуны белдергән булса, соңрак ул икенче мәгънәдә фразеологик берәмлек эчендә килә:

инг. ***A goose quill is more dangerous than a lion's claw*** – Каз каурые арыслан тырнагынна куркынычрак, ягъни язучы сугышчыга караганда күбрәк зыян китерә ала.

КӘККҮК (CUCKOO) – эшсезлек, ялкаулык символы. Шул ук вакытта күкегә карата уңай бәя дә бирелә, бу очракта аны яз, җәй һәм байлык кошы

дип кабул итәләр. Күке тавышын ишеткәч бәхет килсен өчен, тиен акчаларны шылытыратырга кирәк, дигән ышану яшәп килә [3]. Төрки халыкларда күке образы ялгызылык белән бәйле:

тат. ***токымсыз күке*** – өйләнмәүче, дөньяда яшәп тә үзеннән нәсел калдырмаучы;

***дуадак күке төсле*** – йомыркасын башка кош оясына салып, баласын ояга ташлап, ялгыз баш моңаеп йөргән күке кебек. Баласыз тол яки буйдак кешегә мисалдан.

ТАВЫК (HEN) – Европада тавык тиктормаслык, ана назы символы булып килә. Татар фразеологизмнарында тавык кеше үз-үзен тотышын, тышкы кыяфәтен сурәтли:

тат. ***Сукыр тавык*** – белемсез, аңгыра, надан кеше турында;

***Кыртланган тавык*** – чебиле тавык, чеби анасы. Кайбер ананың баласына якын килергә дә ярамыйча, керт-керт килеп чәбәләнеп торуына мисалдан киная;

***Карчыгадан калган тавык шикелле*** – кыяфәте калмаган, өтек, йолкыш, хәчтерүш, сәләмә димәктән;

КАРЛЫГАЧ (SWALLOW) – традицион яз хәбәрчесе. *Бер карлыгач килеп яз булмый* (Бер кеше генә нәрсә дә булса эшләсә, ул зур нәтиҗәләргә ирешә алмый) фразеологизмы шушыннан килеп чыккан.

Мөселманнарга карлыгач үтерү гөнаһ санала, чөнки кайчандыр, аларның ышанулары буенча, карлыгач кешеләрне еланнан коткарган, дип санала. Мондый риваять яшәп килгән: имеш елан белән иблис җир йөзендә бер кеше дә калдырмаска сөйләшкәннәр. Иблис еланга кешелекне ничек бетерергә кирәклеге турында хат язып биргән. Моның турында карлыгач белеп ала һәм шул хатны урлый. Елан аның артыннан куып китә, койрыгын өзеп ала, шулай карлыгачнын икегә аерылган койрыгы барлыкка килә. Шул вакыттан бирле карлыгач белән елан мәңгелек дошманнар булып калганнар һәм карлыгач кырда оя корырга курка, өйләрдә һәм мәчетләрдә оя

кора икән. Әгәр дә кемнең дә булса өендә карлыгач оя кора икән, бу шул йортта яшәүчеләргә иминлек, тынычлык билгесе булып тора.

ӘТӘЧ (COCK) – батырлык, уяулык һәм ышанычлылык символы; таң хәбәрчесе, кояш билгесе һәм әтәчкә хас шушы сыйфатлар тәккәберлек, үзен башкалардан өстен тоту сыйфатларына караганда күбрәк таралган:

тат. ***Беренче әтәч*** – ярты төн булганда кычкырган әтәч тавышы. Элек авылларда төнге сәгать хисабын әтәч кычкыруы белән санаудан. Төн уртасыннан таң атканчыга кадәр – 3 әтәч. Шуңа карап төнлә сәхәргә торганнар;

***Йомыркадан чыкканчы әтәч булган*** – әдәбият, сәнгать я гыйлем мәйданына аяк басу белән үзеннән элгәреләрне бәреп егарга, “мин” дип кычкырырга ашыгучы дәгъвачыл яшь кешеләргә карата әйтелә;

инг. ***Every cock crows on its dunghill*** – Һәр әтәч үз чүплегендә батыр, ягъни күп вакытта кеше үз танышлары арасында гына батыр булып кылана, чит җирдә исә сүз дә әйтә алмый.

Борынгы Грециядә әтәч изге кошлардан саналган, шуңа күрә аны корбан итәргә ярамаган. Ислам динендә дә кошларга игътибар зур булган, еш кына алар изгеләштерелгән.

ҮРДӘК (DUCK) – гаилә бәхете, тугрылык билгесе. Фразеологизмнарда күбрәк үрдәкләрнең тышкы кыяфәте һәм үз-үзләрен тотышлары чагылыш тапкан:

тат. ***сер тотмас үрдәк*** – сер тотмый торган, бер белгәнен теләсә кая чәчеп-түгеп йөрүчегә карата әйтем;

***башчы үрдәк алдан очар*** – гел беренче булырга ял раткан яисә кешеләрне үзе артыннан ияртә торган кеше гел алда бара;

инг. ***a lame duck*** – “аксак үрдәк”, мескен, берни дә булдыра алмаган кеше;

Кош атамасы кергән татар һәм инглиз теле фразеологизмнарын йөрәнү катлаулы лингвокультурологик мәсьәләнең бер аспекты булып тора. Күпчелек фразеологик эквивалентлар барлыкка килүе, кошларның тышкы кыяфәтләре һәм үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән бәйле. Бу үзенчәлекләрне барлык халыклар да бертөрле күрергә мөмкин. Халыкларның дөньяга

карашлары, дини күзаллаулары, эшчәнлекләре һәм гомумән, халык яшәешенең барлык үзенчәлекләре дә фразеологизмнар, мәкалъ һәм әйтемнәрдә чагылыш тапкан. Халыкның тормыштагы тискәре һәм уңай сыйфатларга, кеше характерының үзенчәлекләренә карата бәя-хөкемнәре, тәнкыйди карашлары шулай ук фразеологизмнарда урын алып тора: тат. ***каз оясы*** – тузган өй; ***кикрикле тавык*** – ирләшкән, иренә командир булган кайбер хатын-кызга карата әйтем; ***кара карга*** – аңсыз, кара надан; ***авызына саескан төкергән*** – юкны сайраучы, такылдык; ***чыпчыкның да үз бизмәне*** – ёәркемнең үз мөмкинлегенә күрә үз чамасы димәктән һ.б. инг. ***white crow*** – ак карга; ***sing like a nightingale*** – матур җырлау; – ***chatter like a magpie*** – буш сүз сөйләп утыру; ***swim like a duck*** – яхшы йөзү; ***gay as lark*** – шат күңелле һ.б.

Шулай ук татар һәм инглиз теле фразеологизмнары семантикасы күпчелек очракларда кешегә юнәлдерелгән, һәм шунысын билгәләп үтәргә кирәк: алар күбесенчә кешенең тискәре якларын сыйфатлау өчен кулланлыла. Кеше һәрвакыт яхшыны тиешле хәл дип таба, начарны исә авыр кабул итә һәм шуңа күрә моны ничек тә булса бәяләргә тырыша. Мәсәлән, ***тавык,*** татарларда да, инглизләрдә дә, әкрен, бик үк акыллы түгел, тик үзенекен эшләп йөрүче йорт кошы буларак күзаллана. Моннан чыгып, бу орнитоним кергән фразеологизмнар кешенең шуңа охшаш якларын характерлый. Димәк, тавык орнитонимы кергән фразеологизмнар кешенең тискәре сыйфатларын күрсәтәләр. ***Әтәч***, горур табигатьле, башкаларга баш ими торган, һәр нәрсәдә үзен беренче итеп күрсәтергә омтылган, кызу канлы кош. Кешеләрдә булган шушы сыйфатларны: горурлык, тәкәбберлек, мин-минлек – әтәч орнитонимы кергән фразеологизмнар ачып бирә. ***Күке*** орнитонимы, дөреслегенә инанган булу-булмавына карамастан, һәр нәрсәдә үз белдегенә генә таянып фикер йөрткән кешегә карата кулланыла. Кирәкмәгәнне бытбылдап йөрүче, бер туктаусыз сөйләшүче кеше ***үрдәк*** белән ассоциацияләнә. Бу атамалар, ике телдә дә шул рәвешле күзаллана, әмма аларның кулланылыш ешлыгы төрлечә.

## Литература

1. *Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге / Н. Исәнбәт. Яр Чаллы: "Идел йорт" нәшрияты, 2001. 236 б.

2. Краткая энциклопедия символов // URL: http://www.symbolarium.ru (дата обращения 23. 04. 2019).

3. Словарь символов // URL:www.gumer.info/bibliotek_Buks/Culture/JekTresidder (дата обращения 20.04.2019)

4. Collins Cobuild Idioms dictionary. Heinle ELT, 2012. 576 p.

5. The idioms. The largest idioms dictionary // URL: https://www.theidioms.com/dont-count-your-chickens-before-they-hatch/ (датаобращения 23. 04. 2019).

6. The symbol book // URL: http://www.symbolsbook.ru (дата обращения 25. 04. 2019)

7. What's your sign // URL: http://www.whats-your-sign.com/raven-symbolism (дата обращения 25. 04. 2019)

## References

1. Isənbət, N. Tatar teleneң frazeologik sүzlege [Phraseological dictionary of the Tatar language] / N. Isənbət. Yar Chally: "Idel iort" nəshriyaty, 2001. 236 b. (In Tatar)

2. *Kratkaya entsiklopediya simvolov* [The concise encyclopedia of symbols] // URL: http://www.symbolarium.ru (data obrashheniya 23. 04. 2019). (In Russian)

3. *Slovar' simvolov* [The dictionary of symbols] // URL: www.gumer.info/bibliotek_Buks/Culture/JekTresidder (accessed: 20.04.2019). (In Russian)

4. Collins, Cobuild Idioms dictionary. Heinle ELT, 2012. 576 p. (In English)

5. The idioms. The largest idioms dictionary // URL: https://www.theidioms.com/dont-count-your-chickens-before-they-hatch/ (accessed: 23.04.2019). (In English)

6. The symbol book // URL: http://www.symbolsbook.ru (accessed: 25.04.2019). (In English)

7. What's your sign // URL: http://www.whats-your-sign.com/raven-symbolism (accessed: 25.04.2019). (In English)

**Авторы публикации**
***Сахибуллина Кадрия Азатовна –***
*старший преподаватель*
*Казанский федеральный университет*
*E-mail: kadria85@yahoo.com*

**Authors of the publication**
***Sakhibullina Kadriia Azatovna –***
*senior teacher*
*Kazan Federal University, Kazan.*
*E-mail:kadria85@yahoo.com*

**УДК 913.1**

# БАЛТСКАЯ ГИДРОНИМИЯ ВОЛГО-КАМСКОГО РЕГИОНА

***О.Д. Федченко***

*vukby@yandex.ru*

***Независимый исследователь, Брянск, Россия***

**Аннотация**. Статья посвящена лингвистическому анализу гидронимов республик Башкортостан, Татарстан, Чувашии. Рассматривается происхождение названий значительных (протяженностью около 100 км и более) рек Волго-Камского региона. Произведена систематизация гидронимов, получивших имя в балтской языковой среде. Названия рек имеют этимологию, родственную таким понятиям, как река, русло, поток, течение. Предложенная статья дает возможность уточнить археологические и исторические аспекты жизни древних людей в Поволжье и Прикамье. Подтверждается мнение, что племена боевых топоров были местным населением на территории Волго-Камского региона до появления там финноугорских и тюркских народов.

**Ключевые слова**: гидронимы, этимология, Казань, Уфа, балтизмы, Башкирия, Татария, Чувашия, Кама, Волга.

**Для цитирования**: Федченко О.Д. Балтская гидронимия волго-камского региона. *Казанский лингвистический журнал*. 2019; 4 (2): 22–38.

# BALTIC HYDRONONY OF THE VOLGA-KAMA REGION

***O.D. Fedchenko***

*vukby@yandex.ru*

***Independent Researcher, Bryansk, Russia***

**Abstract.** The article is devoted to linguistic analysis of the hydronyms of the republics of Bashkortostan, Tatarstan, Chuvashia. The origin of the names of significant (length of about 100 km or more) rivers of the Volga-Kama region is considered. The taxonomy of the hydronyms that have received a name in the Baltic language environment is systematized. The names of the